**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Уразлы авыл җирлеге Кече Карамалы авылында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

12 нче декабрь 2019 ел № 3

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 нчы елның 27 нче ноябрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Уразлы авыл җирлеге территориясе, Кече Карамалы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;
- кышкы юлларны карап тоту;
- чүп үләннәрен чабу;
- күмү урыннарын карап тоту һәм ремонтлау;».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 111 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 61 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 61 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге составына керүче Кече Карамалы авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Уразлы авыл җирлеге территориясе, Кече Карамалы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;

- Кышкы юлларны карап тоту;
- Чүп үләннәрен чабу;
- Күмү урыннарын карап тоту һәм ремонтлау;» соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. 2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Уразлы авыл җирлеге территориясе, Кече Карамалы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:

- Җирлек эчендәге юлларны ремонтлау;
- Кышкы юлларны карап тоту;
- Чүп үләннәрен чабу;
- Күмү урыннарын карап тоту һәм ремонтлау.

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Уразлы авылы, Тынычлык урамы, 7;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Кече Карамалы авылы, Кече урамы, 1;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Сатлыган авылы, Урта урамы, 1, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Уразлы авыл җирлеге
башлыгы: М.Г.Хәмидуллин